**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 17 февралендәге 489 номерлы карары**

**«Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, территорияне планлаштыруның мондый проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 9 сентябрендәге 2821 номерлы «“Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең магистраль челтәрләре” линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары нигезендә, «Татарстан Республикасының пространстволы планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе гаризасына таянып, **карар бирәм**:

1. «Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм

«Экорайон» территорияләре өчен хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (1 нче этап), ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (2 нче этап), планлаштырыла торган сервитутлар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) тыш, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чykkannan соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 17 февралендәге
489 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты**

Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең магистраль челтәрләре» линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы (1-6 битләр).


II. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турында нигезләмә.


III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы (1-5 битләр).

IV. Территорияне ызанлау проекты. Территорияне ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (1 нче этап), ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (2 нче этап), планлаштырыла торган сервитутлар чикләрендәге характерлы нокталар координатлары исемлеге белән текст өлеше.

Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (1 нче этап), ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (2 нче этап), планлаштырыла торган сервитутлар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

**I. Территорияне планлаштыру проекты.**
**График өлеш. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы**
**1 бит**







**Условные обозначения**

- Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
- Границы кадастровых кварталов
- Граница земельного участка
- Границы зон планируемого размещения линейных объектов
- 7 — Номера характерных точек границ зон планируемого размещения линейных объектов
- Дествующие красные линии улично-дорожной сети
- К1н — Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации
- К2н — Сети напорной дождевой канализации
- К2 — Сети дождевой канализации
- Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (ЛОС1)
- Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (КНС1)


3 бит




**Условные обозначения**

- Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
- Границы кадастровых кварталов
- Граница земельного участка
- Границы зон планируемого размещения линейных объектов
- 7 Номера характерных точек границ зон планируемого размещения линейных объектов
- Дествующие красные линии улично-дорожной сети
- К1н Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации
- К2н Сети напорной дождевой канализации
- К2 Сети дождевой канализации
- Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (ЛОС1)
- Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (КНС1)
- Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации

**4 бит**




**Условные обозначения**

Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки

Границы кадастровых кварталов

Граница земельного участка

Границы зон планируемого размещения линейных объектов

7 Номера характерных точек границ зон планируемого размещения линейных объектов

Дествующие красные линии улично-дорожной сети

К1н Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации

К2н Сети напорной дождевой канализации


К2 Сети дождевой канализации

Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (ЛОС1)


Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (КНС1)

Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации

# 5 бит


С
147
146
201
200
148
149
199
198
150
151
197
196
152
153
154
195
194
193
155
156
157
158
192
191
190
189
188
186
185
Условные обозначения
Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
Границы кадастровых кварталов
Граница земельного участка
Границы зон планируемого размещения линейных объектов
7
Номера характерных точек границ зон планируемого размещения линейных объектов
Дествующие красные линии улично-дорожной сети
К1н
Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации
К2н
Сети напорной дождевой канализации
К2
Сети дождевой канализации
Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (ЛОС1)
Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (КНС1)
Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации

**6 бит**


С
159
160
161
163
164
166
168
169
171
172
173
174
177
178
180
181
182
183
184
Условные обозначения
Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
Границы кадастровых кварталов
Граница земельного участка
Границы зон планируемого размещения линейных объектов
7
Номера характерных точек границ зон планируемого размещения линейных объектов
Дествующие красные линии улично-дорожной сети
К1н
Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации
К2н
Сети напорной дождевой канализации
К2
Сети дождевой канализации
Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (ЛОС1)
Зона планируемого размещения объекта капитального строительства (КНС1)
Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации

## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

### Урнаштыру өчен планлаштырыла торган линия объектларының, шулай ук урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының атамасы, төп характеристикалары (категориясе, озынлыгы, проект куәте, үткәрү сәләте, йөк көчәнеше, хәрәкәт интенсивлыгы) һәм билгеләнеше

Территорияне планлаштыру проекты һәм линия объекты территориясен ызанлау проекты Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 9 сентябрендәге 2821 номерлы «"Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең магистраль челтәрләре" линия объекты территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары нигезендә әзерләнде.

Әлеге проект Казан шәһәренең Киров районындагы «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен мәйданчыктан тыш үзагышлы һәм басымлы хуҗалык-көнкүреш һәм яңгыр канализациясе челтәрләрен төзүне күздә тота.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан тәкъдим ителгән 2024 елның 9 сентябрендәге 8712/16-29 номерлы техник шартлар нигезендә, су чыгару буенча максималь тоташтырыла торган йөкләнеш тәүлегенә 13954,53 куб.м тәшкил итә, канализацияне «Казан шәһәренең Киров районындагы «Серебряный бор» торак комплексы аша «Несмелов урамыннан алып федераль әһәмияттәге М-7 "Волга" автомобиль юлын төзү» объектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелүче диаметры 800 мм булган басымлы канализация коллекторына тоташтырып, аннары аны «Заречье» канализация насос станциясенә чыгару каралган.

«Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» проектлана торган территорияләреннән чыккан агынты сулар үзагышлы һәм басымлы торбаүткәргечләр буенча җирле канализация насос станцияләреннән КНС-1 канализация насос станциясенә агып төшә һәм алга таба басымлы торбаүткәргечләр буенча «Заречье» канализация насос станциясенең кабул итү коесына суыртыла.

Планлаштыру проекты үз эченә ике челтәр участогын ала.

1 нче участок түбәндәгеләрдән тора:

- «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең 2023 елның 25 августындагы 26716/06/16-29 номерлы техник таләпләре буенча «Юдино» канализация насос станциясеннән К.К1.1-1 камерасы аша агынты суларны КНС-1 канализация насос станциясенә сәгатенә 600 куб.м чыгым белән суыртү өчен диаметры 630 мм булган 648 м озынлыктагы басымлы канализация торбаүткәргече;

- 644 м озынлыктагы су чыгару системасының ышанычлылыгын арттыру өчен билгеләнгән, КНС-1 канализация насос станциясеннән алып К.К1.2-1 камерасы аша 600 мм диаметрлы гамәлдәге коллекторга кадәр диаметры 630 мм булган басымлы канализация торбаүткәргече;

- КНС-1 канализация насос станциясеннән «Заречье» канализация насос станциясенә кадәр агынты суларны чыгару өчен 698 м озынлыктагы гамәлдәге К.К1-2 камерасына кадәр диаметры 630 мм булган басымлы торбаүткәргеч;

- Затонская урамыннан 1 номерлы локаль чистарту корылмасына кадәр 1400 мм диаметрлы 628 м озынлыктагы үзагышлы яңгыр канализациясе торбаүткәргече;

- басымлы торбаүткәргеч – планлаштыру проекты чикләрендә озынлыгы 550 м булган, әлеге планлаштыру проекты чикләреннән читтә урнаштырыла торган 2 номерлы локаль чистарту корылмасыннан ике линиядә диаметры 200 мм булган чистартылган җир өсте суларын чыгару өчен;

- үзагышлы торбаүткәргеч – 650 м озынлыктагы 1 номерлы локаль чистарту корылмасыннан диаметры 1400 мм булган чистартылган җир өсте суларын чыгару өчен.

2 нче участок түбәндәгеләрдән тора:

- «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең 2024 елның 9 сентябрендәге 8712/16-29 номерлы техник таләпләре нигезендә гамәлдәге су агызу системасының ышанычлылыгын арттыру өчен К.К1-3 камерасыннан алып «Заречье» канализация насос станциясенең К-10 кабул итү коесына кадәр диаметры 800 мм булган 1640 м озынлыктагы басымлы торбаүткәргеч.

Басымлы хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләренең озынлыгы КНС-1 дән К.К1.1-1 гә кадәр – 648 м; кызыл линиядән К.К1.2-1 гә кадәр – 609 м; КНС-1 дән К.К1-2 гә кадәр – 3698 м; К.К1-3 тән К-10 га кадәр – 1640 м.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең 2024 елның 21 августындагы 7630/16-29 номерлы хаты нигезендә «Заречье» канализация насос станциясенә тоташтыру ноктасы итеп К-10 камерасы кабул ителгән.

Торбаүткәргечләрне салу күбесенчә горизонталь-авыш бораулау ысулы белән каралган. Торбаүткәргечләр салуның минималь тирәнлеге 630 мм диаметры

өчен 2,40 м һәм 800 мм диаметры өчен 2,60 м итеп кабул ителгән. 630 мм диаметрлы торбаүткәргечләр арасындагы ераклык 2100 мм итеп кабул ителгән.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты тарафыннан «Хәрби шәһәрчек-32» һәм «Экорайон» территорияләре өчен яңгыр һәм кар суларын чыгаруның техник мөмкинлеге турында бирелгән мәгълүмат (2023 елның 20 июлендәге 02-41/1682 номерлы) нигезендә, объект территориясендә шәһәр яңгыр канализациясе челтәрләре булмау сәбәпле, проектта яңгыр канализациясенең ябык типтагы үзагышлы һәм басымлы челтәрен салу, аннары Идел елгасына агызып җибәрү белән локаль чистарту корылмасы төзү каралган.

Үзагышлы һәм басымлы яңгыр канализациясе челтәрен салу ысулы – ачык. Гамәлдәге юллар астында торбаүткәргечләр салу өчен ябык ысул каралган.

Басымлы яңгыр канализациясе челтәрләренең диаметры 160 мм, озынлыгы 548 м һәм 552 м тәшкил итә.

Үзагышлы яңгыр канализациясе челтәрендә 902-09-22.84 типлаштырылган проекты буенча 1000 мм диаметрлы, 1500 мм диаметрлы, 2000 мм диаметрлы җыелма тимер-бетон элементлардан тикшерү коелары, 902-09-46.88 типлаштырылган проекты буенча яңгыр канализациясе камералары, 1400х1000 мм, 1600х1000 мм, 1600х2200 мм, 2300х2300 мм, 2600х2600 мм, 2600х3200 мм, 3000х3000 мм монолит камералар төзү каралган.

Өске агынты сулар 1400 мм диаметрлы үзагышлы коллектор буенча җитештерүчәнлеге 94 л/с булган җир өстендәге агынты суларны чистарту корылмаларына җибәрелә. Аннары, чистартканнан соң, агынты сулар 1400 мм диаметрлы үзагышлы коллектор буенча Идел елгасына чыгару урынына кадәр озатыла.

Машиналар йөрү юлын кисеп үтә торган торбаүткәргечләр полиэтилен, тимер-бетон һәм корыч футлярларда каралган.

Тимер юлларнгы кисеп үтүче торба үткәргеч пыялакомпозитлы торбалардан ясалган футлярда каралган, салу ысулы – ябык.

Идел елгасына яңгыр суларын чыгару су басмый торган итеп өске якта каралган. Чыгу тишегенең аскы өлеше максималь су горизонты дәрәҗәсендә булырлык итеп эшләнгән.

Төзелеш гамәлдәге коммуникацияләргә кагылмый, алар күчерелергә һәм үзгәртеп корылырга тиеш түгел.

**Линия объектларының урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге**

Урнашу урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектлары проектта юк.

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрлары**

Планлаштыру проектын эшләү кысаларында КНС-1 канализация насос станциясе һәм ЛОС-1 локаль чистарту корылмасы төзелеше өчен участоклар каралган.

Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан «коммуналь хезмәтләр күрсәтү» (код 3.1.1) рөхсәт ителгән файдалану төрләре өчен җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә билгеләнми.

**Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелеп килүче саклана торган капиталь төзелеш объектларын (бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объектлар), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектларын урнаштыру белән бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелеш объектлары, шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары юк.

**Линия объектларын урнаштыру белән бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу буенча чараларны гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 августындагы 715 номерлы «Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклау зоналары, Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклауның берләшкән зоналары чикләрен, шулай ук җирләрдән файдалану режимнарын һәм әлеге зоналар чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә су агызу объектларын урнаштыру зонасы Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 98 йорт адресы буенча урнашкан «Кизик монастыренең Надвратная чиркәве», XVII гасыр, федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен кисеп үтә:

ЕОЗ-1 ОКН-Ф «Кизик монастыренең Надвратная чиркәве», XVII гасыр, адресы (урнашу урыны): Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 98 йорт. ЕОЗ-1 чикләрендә җирләрдән файдалану режимы һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр: югарыда аталган карарның 1.6 пункты нигезендә гамәлдәге инженерлык челтәрләрен капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, җир асты ысулы белән яңаларын салу; гамәлдәге инженерлык объектларын (трансформатор пунктын, газ көйләү пунктын һәм башкаларны) капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү рөхсәт ителә;

ЕЗРЗ-2.1, адресы (урнашу урыны): Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, элеккеге Адмиралтейство бистәсе территориясе. ЕЗРЗ-2.1 җирләрдән файдалану режимы һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләр: югарыда телгә алынган карарның 1.6 пункты нигезендә, гамәлдәге инженерлык инфраструктурасын капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, җир асты ысулы белән яңа инженерлык челтәрләре салу; инженерлык инфраструктурасының яңа объектларын (трансформатор пункты, газ көйләү пункты һ.б.) капиталь ремонтлау, реконструкцияләү һәм торгызу рөхсәт ителә.

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль законның (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) 28, 30, 31, 32, 36, 45.1 статьяларына ярашлы рәвештә, бүгенге көнгә кадәр тикшеренүләр үткәрелмәгән урыннарда түбәндәгеләр кирәк:

- 73-ФЗ номерлы Федераль законның 45.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә җир, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшләр йогынтысына дучар булган

җир кишәрлегенә археологик разведка юлы белән тарихи-мәдәни экспертиза үткәрүне һәм финанслауны тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетына җир, төзелеш, хуҗалык һәм башка эшләр йогынтысына дучар булган җир кишәрлегендә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектларның булуы яисә булмавы билгеләнә торган тикшеренү нәтиҗәләрен үз эченә алган документацияне, шулай ук күрсәтелгән документациягә (яисә җир кишәрлегенә) дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен тапшырырга.

Карап тикшерелә торган территориядә археологик мирас объектлары, шулай ук мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектлар табылган очракта, түбәндәгеләрне башкару кирәк:

- проект документациясе составында ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында яисә кырда башкарыла торган археологик коткару эшләрен уздыру турында бүлекне яки ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектын яисә уздырыла торган эшләрнең күрсәтелгән мәдәни мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган кырда башкарыла торган археологик коткару эшләрен уздыру планын эшләргә;

- ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү чараларын нигезли торган документлар яисә документлар бүлеге буенча дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсен алырга һәм аны күрсәтелгән документлар белән бергә килештерү өчен Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетына тапшырырга;

- ачыкланган мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү чараларын нигезли торган килештерелгән документациядә күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

## Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Проект документларында әйләнә-тирә мохитне саклау буенча чараларны күздә тотарга кирәк, чөнки үзагышлы һәм басымлы хуҗалык-көнкүреш һәм яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү чорында төзелеш техникасы әйләнә-тирә мохиткә антропоген йогынты ясау чыганагы булачак. Эксплуатацияләү чорына, аварияләрне дә кертеп, экологиягә куркыныч янау очракларын киметүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләү зарур.

Планлаштыру проекты территориясендә өлешчә «“Дубки” массивы» урнашкан. Татарстан АССР Министрлар Советының 1985 елның 29 декабрендәге 683 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 29 декабрендәге 644 номерлы карары нигезендә «“Дубки” массивы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле булып тора. Проектлана торган линия объектлары «“Дубки” массивы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәлен кисеп үтми. Табигать һәйкәленең чикләре турындагы белешмәләр Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертелгән, зона һәм территориянең реестр номеры – 16:50-6.3451.

Планлаштырыла торган эшләр бары тик линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә генә башкарылачак. Линия объектларын, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук төзелешне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтны һәм агымдагы ремонтны оештыру «“Дубки” массивы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләрендә гамәлгә ашырылмаячак.

Планлаштырыла торган эшләр вакытында чикләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 мартындагы 237 номерлы карары белән расланган табигать һәйкәлен махсус саклау режимын үтәргә кирәк.

**Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48.1 статьясы нигезендә хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең проектлана торган магистраль челтәрләрен аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм уникаль объектларга кертергә ярамый, шулай ук 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында»гы федераль законның 2 статьясы нигезендә куркыныч җитештерү объектларына кертергә ярамый.

Хуҗалык-көнкүреш канализациясенең һәм яңгыр канализациясенең проектлана торган магистраль челтәрләре янгын чыгу һәм шартлау куркынычы булган объект булып саналмый, чөнки проектлана торган объектта техноген характердагы гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы тудыра торган җиңел янып китүчән, янгын чыгу һәм шартлау куркынычы булган матдәләр

җитештермиләр, кулланмыйлар, эшкәртмиләр, сакламыйлар яки транспортлаштырмыйлар.

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматы (2025 елның 25 июнендәге 4060/С4-4-4 номерлы хат) буенча, планлаштыру проекты территориясенең бер өлеше химик зарарлану мөмкинлеге булган зонага эләгә (зона характеристикасы тарату өчен чикләнгән мәгълүмат булып тора), гражданнар оборонасы буенча килеп чыгарга мөмкин булган куркынычның башка зоналарына эләкми.

Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр өлешендә Казан шәһәр округының Генераль планы материалларыннан алынган мәгълүмат тарату өчен чикләнгән мәгълүмат булып тора һәм, Россия Федерациясе законнарын исәпкә алып, проектлаштыруның киләсе стадиясендә төгәлләштерелергә тиеш.

Техник хисаплар нигезендә, инженер-геологик эзләнүләр нәтиҗәләре буенча (00БП-006746-ИГИ, 00БП-006747-ИГИ1) түбәндәге куркыныч табигый физик-геологик процесслар һәм күренешләр ачыкланды. Алар территориянең өске һәм тирәнлектәге грунт массивларының тотрыклылыгына тискәре йогынты ясарга мөмкин:

1) КНС-1 территориясеннән Идел елгасына чыга торган башына кадәр үтүче басымлы яңгыр канализациясе участогында – су басу, туң күтәрелү.

2) КНС-1 дән К.К1.1-1 һәм К.К1.2-1 гә кадәр, КНС-1 дән К.К.1-2 гә кадәр, К.К1-3 тән «Заречье» канализация насос станциясенең кабул иту резервуарына кадәр үтүче басымлы хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре участогында – специфик грунтлар, су басу, туң күтәрелү, шулай ук бу территориядә карст-суффозия процесслары үсеше дә мөмкин.

Инженер-гидрометеорологик тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча (116-2023-ИГМИ, 117-2023-ИГМИ) мөмкин булган куркыныч метеорологик күренешләр проектлана торган объектка йогынты ясамаячак, проектлана торган объектны төзү чорында һәм аны эксплуатацияләү чорында гидрометеорологик характеристикаларның үзгәрүе фаразланмый. Территория сезонлы су баса торган дип санала, Куйбышев сусаклагычының һәм Казансу елгасы тамагының җир өсте сулары проектлаштыру объектына тискәре йогынты ясамаячак.

Планлаштыру проекты территориясе буенча гамәлдәге газ бүлү үткәргечләре уза. Урта һәм югары басымлы газүткәргечләр куркыныч җитештерү объектларына керә, аларда 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать иминлеге

турында»гы федераль закон нигезендә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгарга мөмкин.

Вертикаль факеллы янудагы җылылык нурланышының интенсивлыгын иң ихтимал авария баларак исәпләү Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2024 елның 26 июнендәге 533 номерлы «Җитештерү объектларында янгын чыгу куркынычының исәп зурлыкларын билгеләү методикасын раслау турында»гы әмере нигезендә башкарылды.

Брезент кием кигән кеше өчен куркынычсыз ераклыкта (4,2 кВт/кв.м) вертикаль факел януыннан җылылык нурланышының интенсивлыгы түбәндәгечә булачак:

- урта басымлы газүткәргеч Ø89 Г2 – 19,1 м;
- урта басымлы газүткәргеч Ø250 Г2 – 43,3 м;
- урта басымлы газүткәргеч Ø300 Г2 – 49,9 м;
- югары басымлы газүткәргеч Ø200 Г4 – 55,4 м;
- югары басымлы газүткәргеч Ø300 Г4 – 76,0 м;
- югары басымлы газүткәргеч Ø500 Г4 – 112,7 м.

Техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда куркыныч янау мөмкинлеге булган зоналар чикләре график материалларда күрсәтелгән.

Шулай итеп проектлаштыруның алдагы стадияләрендә «Гражданнар оборонасы чаралары исемлеге, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары» бүлеген эшләргә кирәк түгел.


Шул ук вакытта проектлауның алдагы стадияләрендә түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк:

1. Линия объектын планлаштыру проекты территориясенең бер өлеше химик зарарлану ихтималы булган зонага эләгүе;

2. Газ бүлү үткәргечләрендәге авария вакытында территориянең техноген характердагы мөмкин булган гадәттән тыш хәл зоналарына эләгүе.


## III. Территорияне ызанлау проекты. График өлеш. Территорияне ызанлау сызымы

**1 бит**



# 2 бит



## Условные обозначения

Границы элементов планировочной структуры

Граница земельного участка

Границы образуемых участков (1 этап)

Границы образуемых участков (2 этап)

Дествующие красные линии улично-дорожной сети

16:50:190203:374-ЗУ Условные номера образуемых земельных участков (1 этап)

**ЗУ1** Условные номера образуемых земельных участков (2 этап)

К1н Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации


Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации

К2н Сети напорной дождевой канализации

К2 Сети дождевой канализации

# 3 бит




## Условные обозначения

- Границы элементов планировочной структуры
- Граница земельного участка
- Границы образуемых участков (1 этап)
- Границы образуемых участков (2 этап)
- Дествующие красные линии улично-дорожной сети
- 16:50:190203:374-ЗУ Условные номера образуемых земельных участков (1 этап)
- **ЗУ1** Условные номера образуемых земельных участков (2 этап)
- К1н Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации
- Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации
- К2н Сети напорной дождевой канализации
- К2 Сети дождевой канализации

# 4 бит




## Условные обозначения

Границы элементов планировочной структуры

Граница земельного участка

Границы образуемых участков (1 этап)

Границы образуемых участков (2 этап)

Дествующие красные линии улично-дорожной сети

16:50:190203:374-ЗУ Условные номера образуемых земельных участков (1 этап)

ЗУ1 Условные номера образуемых земельных участков (2 этап)


К1н Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации

Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации

К2н Сети напорной дождевой канализации

К2 Сети дождевой канализации

**5 бит**


С
Условные обозначения
Границы элементов планировочной структуры
Граница земельного участка
Границы образуемых участков (1 этап)
Границы образуемых участков (2 этап)
Дествующие красные линии улично-дорожной сети
16:50:190203:374-ЗУ Условные номера образуемых земельных участков (1 этап)
ЗУ1 Условные номера образуемых земельных участков (2 этап)
К1н Сети напорной хозяйственно-бытовой канализации
Точка подключения напорной хозяйственно-бытовой канализации
К2н Сети напорной дождевой канализации
К2 Сети дождевой канализации

## IV. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше

### Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге

Линия объекты 2 участоктан гыйбарәт:

- 1 нче участок – КНС-1 дән К.К1.1-1 һәм К.К1.2-1 гә кадәр, КНС-1 дән К.К.1-2 гә кадәр кадәр басымлы хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләрен, шулай ук КНС-1 территориясеннән Идел елгасына чыга торган башына кадәр яңгыр сулары чыгару канализациясен төзү.
- 2 нче участок – К.К1-3 тән «Заречье» канализация насос станциясенең кабул иту резервуарына кадәр басымлы хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләрен төзү.

## Ясала торган җир кишәрлекләре исемлеге (этаплап)

| № | 1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары | 1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы | Алардан 1 нче этап җир кишәрлекләре ясалган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары | 1 нче этаптагы җир кишәрлекләренең ясалу ысулы | 2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары | 2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы | Алардан 2 нче этап җир кишәрлекләре ясалган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары | 2 нче этаптагы җир кишәрлекләренең ясалу ысулы | Ясала торган җир кишәрлекләре җирләренең категориясе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:000000:29801:ЗУ1 | 1338 | 16:50:000000:29801 | Саклап калу юлы белән бүлү | ЗУ1 | 1977 | 16:50:000000:29801:ЗУ1<br>16:50:280303:ЗУ1 | Берләштерү | Торак пунктлар җирләре |
| 2 | 16:50:280303:ЗУ1 | 639 | - | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән ясалу | | | | | |
| 3 | 16:50:000000:29801:ЗУ2 | 6004 | 16:50:000000:29801 | Саклап калу юлы белән бүлү | ЗУ2 | 10320 | 16:50:000000:29801:ЗУ2<br>16:50:280304:19:ЗУ1<br>16:50:000000:17380:ЗУ1<br>16:50:280303:ЗУ2<br>16:50:190301:ЗУ1<br>16:50:280304:ЗУ1<br>16:50:190301:374:ЗУ1 | Берләштерү | Торак пунктлар җирләре |
| 4 | 16:50:280304:19:ЗУ1 | 295 | 16:50:280304:19 | Саклап калу юлы белән бүлү | | | | | |
| 5 | 16:50:000000:17380:ЗУ1 | 3390 | 16:50:000000:17380 | Саклап калу юлы белән бүлү | | | | | |
| 6 | 16:50:280303:ЗУ2 | 43 | - | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән ясалу | | | | | |
| 7 | 16:50:190301:ЗУ1 | 30 | - | Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән ясалу | | | | | |

| № | 1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары | 1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы | Алардан 1 нче этап җир кишәрлекләре ясалган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары | 1 нче этаптагы җир кишәрлекләренең ясалу ысулы | 2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары | 2 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы | Алардан 2 нче этап җир кишәрлекләре ясалган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары | 2 нче этаптагы җир кишәрлекләренең ясалу ысулы | Ясала торган җир кишәрлекләре җирләренең категориясе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | 16:50:280304:ЗУ1 | 114 | - | Дәүләт яки муниципаль милектәге җирдән ясалу | | | | | |
| 9 | 16:50:190301:374:ЗУ1 | 444 | 16:50:190301:374 | Саклап калу юлы белән бүлү | | | | | |

Искәрмә:

Саклап калу юлы белән бүлү – Бүленгән җир кишәрлеген саклап калып, чикләре үзгәртелгән килеш бүлү.

Ясала торган җир кишәрлекләре гомуми файдалану территориясенә кермиләр.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматы буенча (2025 елның 3 июлендәге 14-5369 номерлы хат) планлаштыру проекты чикләре урман фонды җирләренә кагылмый.

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан алынган мәгълүматларга караганда, ясала торган ЗУ1 һәм ЗУ2 җир кишәрлекләре чикләрендә күчемсез милек объектлары юк.

**Ясала торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары, дәүләт ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервлау һәм (яисә) мәҗбүри алу күздә тотыла торган гамәлдәге җир кишәрлекләренең кадастр номерлары яки элек бирелгән башка дәүләт исәп номерлары, аларның адреслары яисә урнашу урыннары тасвирламасы**

**Ясала торган һәм дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен мәҗбүри алынырга тиешле гамәлдәге җир кишәрлекләре исемлеге**

| № | 1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең шартлы номерлары (1 нче этапны алу) | 1 нче этапта ясала торган җир кишәрлекләренең мәйданы | Гамәлдәге җир кишәрлекләренең кадастр номеры | Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен мәҗбүри алу турында белешмәләр | Гамәлдәге җир кишәрлекләренең адресы яки урнашу урыны тасвирламасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:000000:29801:ЗУ1 | 1338 | 16:50:000000:29801 | өлешчә мәҗбүри алу | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Киров районы |
| 2 | 16:50:000000:29801:ЗУ2 | 6004 | 16:50:000000:29801 | өлешчә мәҗбүри алу | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Киров районы |
| 3 | 16:50:190301:374:ЗУ1 | 444 | 16:50:190301:374 | өлешчә мәҗбүри алу | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Киров районы |

**Линия объекты ачык сервитут шартларында урнаштырылырга мөмкин булган гамәлдәге җир кишәрлекләренең кадастр номерлары исемлеге**

| № | Гамәлдәге җир кишәрлекләренең кадастр номерлары | Гамәлдәге җир кишәрлекләренең адресы яки урнашу урыны тасвирламасы | Линия объектының урнашу урыны тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:000000:1013 (ЕЗП 16:50:000000:34) | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Казан шәһәре, Киров районы, «Россия тимер юллары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән кисешкән урын | Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләренең «Россия тимер юллары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән кисешкән урыны |
| 2 | 16:50:000000:1013 (ЕЗП 16:50:000000:34). | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Казан шәһәре, Киров районы, «Россия тимер юллары» җаваплылыгы | Яңгыр канализациясе челтәрләренең «Россия тимер юллары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән кисешкән урыны |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | чикләнгән җәмгыяте белән кисешкән урын | |
| 3 | 16:50:000000:37302 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Казан шәһәре, Киров районы | Ленин исемендәге химия заводыннан тимер юлның бүлеп алынган полосасы белән кисешкән урын |